Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
«Мөрәле төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет  гомуми белем учреждениесе

# *Хәтерләүдән курыкма син!*
# *Үткәннәрне онытма син!*

(Туган төбәк – Краеведение  номинациясенә)

Язды: 8 сыйныф укучысы
Сафина Илсинә Илфат кызы

Җитәкчеләр: югары категорияле тарих укытучысы
Хамидуллина Альбина Искәндәр кызы,
югары категорияле инглиз теле укытучысы
Мингазова Лилия Тәлгать кызы

2016  ел

Эчтәлек


I. Темага кереш
   1. Теманың актуальлеге.
   2. Теманың эчтәлеген ачу буенча күзәтү
II. Төп өлеш
   1. Мөрәле авылы барлыкка килү тарихы риваятьләрдә.
   2. Авылның ономастик мирасы.
   3. Авылыбыз тарихы XVI – XIX гасырларда.
   4. Гасырлар буена сузылган инкыйраз...
      - Авылыбыз 1920 – 1940 елларда.
      - Авылым Бөек Ватан Сугышы елларында.
      - Авылыбыз тарихы 1950 – 2000 елларда.
   5. Мәктәбем – белем бишегем.
   6. Горурланам авылым синең белән

   Үстергәнсең данлы кешеләр…
III. Йомгаклау
IV. Кулланылган әдәбият

J  Слово автора

На районный смотр-конкурс всвязи с 70-летием Великой Победы, объявленный Исполкомом Кайбицкого муниципального района и Центром внешкольной работы ДО мы подготовили материал, который освещает не только военную тематику, но и другие направления деятельности музея. Школьные музеи сельской местности, в частности наш музей “История села” – универсального характера. Память историческая не может быть однобокой. И тем более, патриотическое воспитание, которое включает в себя разные точки опоры. Ведь основная цель патриотического воспитания – *формирование патриотизма как интегративной характеристики личности*.

Патриотическое воспитание – это процесс становления и развития патриотического сознания, формирования отношения к Отечеству, как национальной ценности, развитие таких качеств личности, как любовь к отчизне, внимание к историческому облику России, духовная связь с народом.

Точки опоры патриотического воспитания это - родина, природа, многогранная культура России и Татарстана, родной язык и сам человек. Мы должны служить Отечеству, служа истине и справедливости. Это ноша очень трудная, но достойная.

С уважением:руководитель музея “История села”
учитель истории Муралинской ООШ РТ Хамидуллина А.И.

# I. Кереш

## 1. Конкурс темасының актуальлеге

Авылымның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным – тәнем белән.
Г. Тукай

Туган җир! Кыйммәтле энҗе – мәрҗәннәргә, иксез – чиксез байлыкка, хәтта зәңгәр күк йөзендә балкучы якты кояш белән алтын айга да тиңе булмаган нәрсә ул! Нинди соң ул минем туган җирем, туып – үскән газиз төбәгем? Моны гади сүзләр белән генә аңлатып бирергә һич тә мөмкин түгел шул!

Авылым, - син бөек илкәемнең
Җанга якын газиз почмагы.
Җылытып яши гомер буе безне
Туган җирнең газиз учагы.
Р. Закиров

Туган якның гүзәллеген, аның сихри матурлыгын һәр кеше күңеле, җаны – тәне белән тоеп яшәргә тиештер. Авыл кешесен бу дөньяда илаһи зат итеп яшәтә торган бер көч бар – ул туган туфракка мәхәббәт. Ул мәңгелек тарту көче. Бу хисне авылда туган кеше генә аңлый:

Аз кирәк бит миңа,
Ипи кыерчыгы, я дә
сөт тамчысы,
Шушы һавам, я дә
шул болытлар.
Аз кирәк бит миңа...
Велимир Хлебников.

Туган авыл, туган туфрак! Минем өчен ул - туган йорт, әби – бабамнар туфрагы, әти – әниемнең, туганнарымның, шушы дөньяның кабатланмас бер кисәге. Шушы җирдә – буыннар бәйләнеше. Әйе, әйе буыннар бәйләнеше. Ә бу бит үзе бер тарих.

Синең гомереӊ –
Тарих өчен бары бер минут.
И. Юзеев

Әйе, безнең гомер, озын, сикәлтәле юллы тарих өчен, шагыйрь дөрес билгеләгәнчә, бары бер минут. Ләкин шушы бер минутлык гомерләрдән гаиләбез, авылыбыз, ил тарихы барлыкка килә һәм шушы тарих безне

дөньяда илаһи затлар буларак яшәтә. Буыннар чылбырында ата – бабаларыбыз нинди эз калдырганын, гомумән, авылыбыз тарихында нинди истәлекле чорлар булганын, шәхес буларак, тирәнрәк беләсем килә.

Шуларны күз алдында тотып, дөньяга карашымны киңәйтү максатыннан, бездә конкурста катнашу уе туды.

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Ни иккәнен, ни чәчкәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар,
Безгә калдырып киткәнен.
Р. Фәйзуллин.

## 2. Теманың эчтәлеген ачу буенча күзәтү.

Туган төбәк тематикасына багышланган конкурста катнашу өчен мин төрле материаллардан файдаландым.

Теләсә нинди тема югары бәяләнсен өчен беренчел чыганаклар, ягъни документаль материаллар кирәк. Ләкин аларны табу һәм әйләнешкә кертү кыен, чөнки архив материаллары, район аерылу сәбәпле, бездә сакланмаганнар. Тема эчтәлеген ачуда безгә Ф. Гарипованың «Авыллар һәм калалар тарихыннан” дигән китабы, матбугат материаллары, авыл аксакалларының истәлекләре, «Авыл тарихы» музеенда саклана торган язма һәм матди экспонатлар ярдәм итте. Жанры буенча, теманың эчтәлеген ачуда файдаланылган язма материаллар, күбесенчә публицистик характерда. Болар барысы да укучыларнын фәнни-тикшеренү эшләрендә гәүдәләнде, һәм мин конкурс тематикасының эчтәлеген шул эшләр аркылы яктыртырга булдым.

Теманың эчтәлеге хронологик яктан, авылның барлыкка килүе турындагы риваятьләрдән башлап, кыскача XX гасыр азагына кадәрге вакыйгаларны үз эченә ала. Шушы эчтәлекне ачу өчен риваятьләргә, фактларга, шулар аркылы төрле вакыйгаларга һәм кеше язмышларына тукталырга булдым. Чөнки шәхесләр биографиясеннән башка авыл тарихы була алмый.

Теләсә нинди кече Ватан тарихы зур Ватан тарихына үрелеп бара һәм, сүз дә юк, бу тарих төрле чорларда ил җитәкчеләре алып бара торган сәясәткә дә бәйләнгән. Шушы сәясәтнең авыл, Бөек Ватан сугышы тарихында нинди эз калдырганын бераз булса да бәян итә алу - безнең максатым.

Вакытында, “Фикер” газетасына мөрәҗәгать итеп, бөек Тукаебыз болай язган: “Уйларыгызны языгыз да, уйны уйга бәйләгез”.Миңа да шул эшкә чумарга вакыт җитте.

## IV. Төп өлеш

### 1. Мөрәле авылы барлыкка килү тарихы - риваятьләрдә

Һәр нигезнең, һәр авылнын,
Һәр каланың үткәне бар...
Р. Фәйзуллин.

Теләсә кайсы авылның барлыкка килүенә карата төрле риваятьләр яши. Шул исәптән, безнең авылның барлыкка килүе турында да төрле риваятьләр бар. Шуларның кайберләренә тукталмакчы булам.

Ветеран укытучы Хәйбуллина Рәшидә әби үзенең истәлекләрендә түбәндәгеләрне бәян итә: «Безнең Мөрәле авылы чама белән 1300 елларда хәзерге авылдан урманга таба бер чокырда, чокыр дигәч тә, чокыр түгел, үзәнлектә урнашкан булган. Авыл элек урнашкан шушы чокыр «Иске йорт чокыры» дип йөртелә. Бу урын бер дә тыныч булмаган, авылны еш кына талаганнар. Халык бу хәлгә түзә алмыйча, «Иске йорт чокыры»н ташлап китеп, хәзерге урынга күченеп килгән. Ул чокырда бер йорт, җимерек хәлдә калган булса да, хәзер дә сакланган. Шуңа күрә, бу урын «Иске йорт чокыры» дип йөртелә. Бу чокыр буйлап инеш агып чыккан. Аның кизләве дә булган. Авыл халкы шушы кизләү янында боламык пешергән һәм бергә җыелышып ашаган. «Боламык кизләве» дигән атама да менә шуннан барлыкка килгән»

Ветеран китапханәче Гыйбадуллина Асия апа сөйләве буенча, авылның шушы беренче урнашкан урыны бер дә тыныч булмаган һәм Миргали исемле өлкән кешенең киңәше белән, халык хәзерге урынга күченгән. Шушы кеше исеменнән авыл Мөрәле дип йөртелә башлаган.

Ә алдан искә алынган хөрмәтле Рәшидә апа истәлекләрендә авыл исеменә карата түбәндәге версия китерелә: «Иске йорт чокыры» буена Мөһергали исемле кеше килеп төпләнгән. Руслар аны Мурали дип йөрткәннәр. Тора – бара авыл да шул исем белән атала башлаган.

Мөрәле авылында дүрт нәсел яшәгән:

- Илмәт нәселе.
- Үтәгән (Үтәмеш) нәселе.
- Сәйкә (Сәйфетдин) нәселе.
- Ширәмәт нәселе.

Авылның хәзерге урыны да бик үк мактаулы түгел, сазламыклы булган бу җир. Юллар салуга карамастан, сазлык җир үзенекен иткән. Хәйбуллин Борһан бабайның әтисе Нәҗметдин баба истәлекләрендә, аның күз алдында Каеп (тау буендагы авыл) алпавытының аты батып үлүе турында искә алына.

Филология фәннәре докторы Ф. Гарипованың «Авыллар һәм калалар тарихыннан» исемле хезмәтендә авылның борынгы тарихы турында түбәндәге мәгълүматлар китерелә: « Е. И. Чернышев мәгълүматлары буенча, Мөрәле авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. 1565 – 1567 елларны эченә алган Зөя өязе Теркәү кенәгәсендә Мөрәле авылы да теркәлгән. Д. А.

Корсаков җыентыгында Мөрәле авылында 82 йомышлы, 4 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә. Бәрле суы янына утырган Мөрәле авылы турында А. Артемьев түбәндәге мәгълүматларны бирә: «Авылдагы 114 хужалыкта 336 ир – ат һәм 323 хатын – кыз яшәгән, анда гыйбадәт кыла торган бер йорт булган”. 1898 елгы хезмәттә Мөрәле авылында татарлар һәм руслар яшәгәнлеге ассызыклана. К. П. Берстель җыентыгында әйтелгәнчә, Мөрәледә барлыгы 1254 татар кешесе яшәгән»[1].

1986 елда күрше Борындык авылы янындагы урманда агач утырткан вакытта укучылар тарафыннан көмеш акчалар тутырылган чүлмәк табыла. Укытучыбыз бу табылдыкны Республика Дәүләт музееның нумизматика бүлеге белгечләренә күрсәткән. Алар бу акчаларның Алтын Урда ханы Мәңгү – Тимер исеменнән сугылган Җучи акчалары икәнлеген һәм республика территориясендә шушы хан исеменнән сугылган акчалар табылдыгының иң күләмлесе булуын билгеләп үттеләр.

Бу факт, авылның Алтын Урда чорында ук яшәгәнлеген дәлилләргә нигез бирә.



Алтын Урда ханы Мәңгү-Тимер исеменнән сугылган
Җучи акчалары (Борындык хәзинәсе)

[1] Ф. Гарипова. Авыллар һәм калалар тарихыннан. – Казан, 1997. 297 бит.

## 2. Авылның ономастик мирасы

Тугайга  чыклар төшкән
Болында – тугайларым.
Тугайда – томаннарым.
Урманда – аланнарым.
Барысы, барысы – минеке.
Шул бәхетле таңнарым.
С. Хәким.

Авыл атамалары безнең борынгы тарихыбызны, данлы үткәнебезне билгели. Алар юкка бирелмәгән: бер ишеләре этнонимга, икенчеләре тарихи вакыйгаларга, өченчеләре кеше исемнәренә, гореф – гадәтләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән.

Мөрәле авылының  микротопонимиясен лексик – семантик яктан түбәндәге өлешләргә бүлеп карарга мөмкин:

1. Кеше исемнәре һәм кушаматларына нигезләнгән микротопонимнар: Гөлминкә чокыры, Гөлҗи әби чокыры, Гобәй коесы, Садри бай күпере.
2. Үсемлек дөньясы белән бәйләнешле микротопонимнар: Карамалы күл һәм Карамалы юл.
3. Географик объектның төсенә карап аталган микротопонимнар: Кызылъяр култыгы.
4. Тормыш – көнкүрешкә бәйле микротопонимнар: Аракы елгасы, Тимерче күпере, Мунчала күле, Боламык кизләве, Иске йорт чокыры, Тегәрҗеп урамы, Лашман тавы (лашманчылар юлы буенда урнашкан).
5. Географик объектның урнашу урынына карап билгеләнгән микротопонимнар: Аръяк, Урман башы урамы, Югары Оч, Түбән Оч, Авыл чыганагы чишмәсе, Бәрле суы бассейны.
6. Географик объектның зурлыгына, формасына карап аталган микротопонимнар: Казыган, Тирән, Таллы, Якты күл.

Бу микротопонимнарның һәрберсенең тарихын кертеп, аерым хезмәт язарга мөмкин. Әмма шулай да мин кайберләренә тукталып китмәкче булам. Чөнки бу микротопонимнарда, билгеләп үтелгәнчә, кеше язмышлары тарихы, зыялылыкның югары критерие булган – хәйрия эшчәнлеге.

Гобәй бай коесы.

Авылның Тегәрҗеп урамында ике кое урнашкан булган, шулар каршында Гобәй бай яшәгән. Коеларны да ул казыткан. Шул вакыт өчен бик әйбәт саналган бишпочмаклы йортында ул  улы Хәлиулла белән гомер кичергән. Гобәй байның авылда урнашкан өч җил тегермәне дә эшләгән. Үлеменнән соң, ул аны ике улы – Хәлиулла һәм Хәмидуллага васыять итеп калдыра.

Садри бай күпере.

Авыл уртасыннан ага торган инешнең ике ягында ике урам урнашкан. Ләкин инеш ярлары бик тирән чокырлы булу сәбәпле, бер урамнан икенчесенә чыгу бик читен булган. Шуны хәл итү уңаеннан, Исмәгыйль бай ике күпер эшләткән. Түбәнгесе, тимерче алачыгына якын урнашканга күрә, «Тимерче күпере» дип, ә югарыдагысы «Садри бай» күпере дип йөртелгән. Садри, Исмәгыйль байда управляющий булып эшләгән. Соңыннан, Исмәгыйль бай Садрины үзе белән бергә яшәргә уллыкка алган һәм бар байлыгын да аңа калдырган. Садри үзе дә баеп китеп, күпер эшләтә. Бүгенге көнгә кадәр бу күпер җимерек хәлдә иде. Анда, бер трактор суга төшеп, кеше үлү очрагы да булды. Күптән түгел " Агрохимсервис" генераль директоры, авылдашыбыз Фәргать Сибгатов тырышлыгы белән күпер яңадан торгызылды, хәйриялек буенча изге эш эшләнде. Изге гамәлләр кылу өчен "Хәйрия елы" игълан иткәнне көтәргә кирәкми, бу - һәрберебезнең кешелек бурычы, Аллаһы Тәгалә хакы өчен яхшылык эшләү.



Мөрәле мәктәбе укучыларының чишмә буен чистарту күренеше

# 3. Авылыбыз тарихы XVI – XIX гасырда

Беркемгә дә яшәү җиңел түгел,
Хакыйкать ул бик тирәндә ята.
Яшәү мәгънәсенә төшеник без,
Узганнарга урап кайта – кайта,
Ялгышларны бәреп вата – вата.
Ф. Яруллин

XVI гасырдан бирле авыл шактый катлаулы тарих юлы үткән. Иван Явыз, безнең крайны Мәскәү дәүләтенә кушканнан соң, бирегә актив рәвештә рус дворяннарын күчереп утырту политикасы башланган. Бу йомышлы катлауга зур җир биләмәләре бирелгән. Безнең авыл күршесендә, Каеп алпавытының шундый биләмәләре булганлыгы билгеле.

Опричнина сәясәтенә бәйле рәвештә, безнең Зөя өязенә Явыз Иван белән килешә алмаган феодаль аксөякләр төркеме дә килә. Авыл янында XVII гасыр ахырында Зөя кушылдыклары - Гөбнә һәм Бәрле елгалары буйлап ныгытылган тозаклар төзелә. Шулай итеп, рус дворяннары үз биләмәләрен ныгыталар. Безнең авыл татар авылы булып кала. Христианлаштыру сәясәте дә авылны читләтеп үтә. Алай да, XX гасыр башына кадәр авылда берничә рус гаиләсе яшәгәнлеге билгеле. Безнең авылдан 30км ераклыкта тоташ чукындырылган керәшен авыллары тезелеп киткән (Мәлки, Хозесан һ. б.)

Безнең авыл Зөя воеводолыгына, ә тора – бара Зөя өязе территориясенә кергән. Авыл халкының социаль хәле катлаулы һәм авыр булган. Авылда йомышлы татарлар һәм ясак түләүче крестьяннар яшәгән. Белүемчә, татар крестьяннары дәүләт крестьяннары булганнар һәм алар имана җирләреннән файдаланганнар. Шул җир фондыннан файдаланган өчен дәүләткә алар төрле җыемнар түләгәннәр. Иң зур җыем – ясак булган. Ул я акчалата, я натуралата алынган. Натуралата акча төрле оброклардан торган. Халык көне – төне тир түгеп эшләп, шушы ясакка түләрлек бал – май, хайван тиресе, икмәк, йомырка һәм башка бик күп продуктлар җыерга тырышкан. Шуның өстенә, урман – күлләрдән файдаланган өчен дә түләү булган. Урман кисү, төрле тозаклар, ныгытмалар төзү дә халык җилкәсенә төшкән. Рус крестьяннары бирегә күчеп килгәч, (күрше Федоровское авылы) авыл кешеләре яшелчәләр үстерергә өйрәнгәннәр.

Авылда һөнәрчелекнең төрле төрләре: капчык, чыпта җитештерү, сумала, дегет куу, агач ләгәннәр, кәнди, тәлинкәләр, чүлмәкләр, чиләк, мичкәләр ясау, палас сугу станогы, май ачлау өчен гөбеләр, иләкләр, он тагараклары, бөртеклеләрне төер өчен килеләр, сарык тиресен эшкәртеп каеш – сбруй әйберләре, камытлар ясау үсеш алган.



Борынгыдан алып XX гасыр урталарына кадәр кулланылган хуҗалык кирәк – яраклары экспозициясенең мәктәп музеендагы күренеше.

Халык тимерчелек белән XVIII гасырда гына шөгыльләнә башлаган, татарларга сәүдә итү хокукы да XVII гасыр азагында гына бирелгән.

Билгеләп үтелгәнчә, татар крестьяннары, дәүләт крестьяннары булсалар да, салымнар күп булу сәбәпле, хәлләре җиңелдән булмаган. XVII гасыр азагында, шул сәбәпле килеп чыккан халык күтәрелешләре кайтавазы безнең яклар белән дә бәйле. Мәсәлән, болганчык еллар чорында В. Шуйский хөкүмәтенә каршы халык арасында бердәм позиция булмау сәбәпле, Россиядә һәм шул исәптән безнең күрше – тирә якларда да халык фетнәләре күтәрелә. 1609 елда безнең **күрше Борындык авылы янында** Казан воеводасы Ф.И.Шереметев җитәкчелегендәге патша гаскәренең фетнәчеләрне тар – мар итүе билгеле.[1]

С. Разин җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе дә безнең якны читләтеп үтмәгән. С. Разин Сембер шәһәрен кулында тотканнан соң, Казанга да килергә исәп тота. Моңа каршы Ю. Барятинский җитәкчелегендәге гаскәрләр Казаннан Сембергә юнәләләр. Алар юлда барганда безнең күрше **Колаңгы авылы янында** 3 меңлек крестьян отряды белән бәрелешәләр. Крестьян отрядлары тар – мар ителә. Безнең борынгы бабаларыбыз да шушы бәрелешләрдә катнашып, башларын салганнардыр…

Һәр карыш җир сугарылган
Шаһит җаннар каннарында.
Үткән яулар шәүләсе бар
Туган якның таңнарында.

XVIII гасырның I яртысы – Петр I реформалары белән бәйле чор. Россиянең халыкара хәлен яхшырту максатыннан, Бөек Петр күп планнар кора. Ә моңа бары тик Россия икътисадын үстереп кенә ирешергә мөмкин

[1] Синицына К. Р. Татарстан һәм татар халкы тарихы. – Казан: Мәгариф, 2001. – 44 бит.

була. Көнбатышка сәүдә юллары ачу – ирешелгәннәрнең иң мөһиме. Сәүдә һәм сугыш кораблары төзү өчен адмиралтействолар ачыла, шул исәптән Казанда да.

Казан губернасы «корабльгә яраклы» урманнарга бай саналган. Казан тирәсендәге имәнлекләрне карап чыккач, Петр 1 башка верфьләрне дә имән агачы белән тәэмин итәргә боерган. Казан губернасының барлык территориясеннән дә диярлек, имән агачларын кисеп, адмиралтействога ташыган лашманчы крестьяннарның авыр хезмәтенең илебез тарихында әһәмияте зур.

Безнең авыл яныннан Урсак урманчылыгы башлана. Элек – электән бу урманнарда сыйфатлы имән агачлары үскән. Нәкъ менә шушы имәннәр корабльләр төзү өчен кулланылганнар да инде. Урсак имәннәре Адмиралтейство верфьләренә барып җиткәнче, зур юл узган. Су юлы белән җибәрү уңышлырак булганлыктан, лашманчылар агачларны безнең авыл аркылы (**Лашман юлы)** Зөя елгасына ташыганнар, ә инде Зөядән сал ярдәмендә Иделгә агызганнар. Бүгенге көндә дә имән үсентеләрен үстереп тарату буенча специальләшкән Кайбыч урман хуҗалыгы, Россия күләмендә бердәнбер булып санала.

XVIII гасырда авылның социаль хәле әллә ни үзгәрешләр кичермәгән. Бу чорда йомышлылар һәм ясак түләүче крестьяннар дәүләт крестьяннары категориясенә кертеләләр. Халык санын алу буенча ревизия үткәрелгәннән соң, ясак җан башыннан алына торган салым белән алыштырыла. XIX гасырда авыл крестьяннарының имана 5 – 13 дисәтинә булган, ә имана оклады 3,82 сумнан 13,36 сумга кадәр җиткән. Шуның өстенә, крестьяннар земство җыемнары түләгәннәр, юллар төзекләндерүдә, олаучылыкта, лашман хезмәтендә эшләгәннәр. Рекрут йөкләмәсе башкарганнар.[1]

Безнең авыл общинасы Кошман волостена буйсынган. Авыл өенең эчендә шамаиллар – матур итеп язылып, бай итеп бизәлгән Коръән аятьләре урнаштырылган каллиграфия үрнәкләре урын алган. Әбием, үзенең әнисе истәлекләреннән чыгып, шул чорны түбәндәгечә бәян итә: "Минем әти - әнием бай гаиләдә яшәгәннәр. Өебездә хуҗалыкта кулланыла торган әйберләрнең барысы да бар иде диярлек. Йортка керү юлында урнашкан мичкә аш пешерә торган казан бастырып куелган. Мич артында тәһарәт алу өчен калай яисә бакыр комганнар һәм зур ләгән тора. Йортның алгы ягында киң сәке, ә аңа түшәкләр түшәлгән, мендәрләр өелгән. Савыт – саба арасында – самовар һәм тимер кружкалар да бар иде. Берничә сандык та: анда әнием өй кирәк – яракларын саклый, ә йортка керү юлында ук кулдан эшләнгән паласлар өебезне бизи иде.

Ирләр дә, хатын – кызлар да җәен киндердән тегелгән киемнәр, ә кышын тун, чикмән яки толып кияләр иде. Ир кешене һәрвакытта түбәтәй, ә хатын – кызларны калфак, яулык яки шәл бизи иде."

---

[1] Мустафина Г. М. Татарстан тарихы. XIX гасыр. – Казан, Мәгариф, 2004. - 25 бит



*Татар өе бизәлеше һәм кием – салымнар үрнәгенең музейдагы  бер күренеше*

## 4. Гасырлар буена сузылган инкыйраз…

- Авылыбыз 1920 – 1940 елларда

XX гасыр башында рус – япон сугышы һәм беренче бөтендөнья сугышы авыл тарихында аерым эз калдыра. Сугыш китергән бәла – казалар авыл кешеләренең язмышында да чагыла. Ахыр чиктә, бу вакыйгалар самодержавиенең һәлакәтенә китерә. Октябрь инкыйлабы, большевикларның властька килүе ил тарихын, кешеләр язмышын астын – өскә китерә.

Октябрь инкыйлабыннан соң безнең авыл Свияжск кантоны Кошман волостена кергән. Большевиклар сәясәте аркасында килеп чыккан гражданнар сугышы авылның социаль хәленә нык тәэсир иткән. Эсерлар программасы нигезендә крестьяннарга бүленгән җир «бөтен кешене дә тигез һәм бертөрле яшәтәбез», дигән идеалның кире ягы гына була.

Гражданнар сугышы вакытында, “хәрби коммунизм” политикасы кысаларында кертелгән продразверсткага каршы авылда 1920 елда «сәнәкчеләр фетнәсе» кабынып китә. Үзләрендә икмәк запасы булган авылының урта хәлле һәм баерак кешеләре көчләп икмәк тартып алу сәясәтенә каршы чыгалар. Бу вакыйгалар турында бабам **Сафин Хафиз** болай язып калдырган: «Волостьтан задание җыярга килгән кешеләргә әти һәм авыл халкы икмәк бирүдән баш тарткан. Бик күп кеше сәнәкләр һәм балталар белән коралланып, «Бетсен коммунистлар һәм гражданнар сугышы!» дип, күл буенда урнашкан мәдрәсә янына җыелганнар. Килгән отрядлар белән бәрелешләр булган. Әтине әле шуның өчен волостька алып китеп, ябып та тотканнар. Халык арасыннан Борһанова Фәрхруй исемле хатынны властьлар белән сөйләшергә вәкил итеп җибәргәннәр».

“Хәрби коммунизм” сәясәтен ЯЭП га (яңа экономик политика) алыштыру да авылда үзенең уңай нәтиҗәләрен бирергә өлгерми, чөнки, беренчедән, 1921 – 1922 елларда авылда халыкка коточкыч ачлык татырга туры килә. Авыл аксакаллары сөйләве буенча, кыш салкын булу сәбәпле, 1921 елның язында уҗым культураларының яртысы тишелми. Атлар, сыерлар һәм сарыкларның баш исәбе бик нык кими. Авылда бик күп кеше Себер якларына чыгып китә. Алар арасында Финляндиягә һәм Маньчжуриягә китүчеләр дә була. Күрше – тирә авылларда кешеләрнең ачтан үлү очраклары да күренә. Икенчедән, ЯЭП ның уңайлыкларын авыл кешеләре үз җилкәләрендә татырга өлгермичә дә калалар, чөнки тоталитар режим төрле юнәлештә үзенең канатын җәя башлый.

20 еллар ахырына авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу бәяләре дәүләт тарафыннан түбән дәрәҗәдә куела. Авылдашыбыз Фәүзия әби бу турыда болай искә ала: «Минем әти һәм аның туганнары барысы да таза тормышлы кешеләр иде. Җыеп алынган икмәк тә шактый була иде. Ләкин әтинең: «Бу юк бәягә икмәкне сатудан ни мәгънә», - дигән сүзләре исемдә калган. Күп кешеләр икмәкләрен яшереп тоталар иде, ә мануфактура әйберләре, киресенчә бик кыйбат иделәр”.

Икмәк кризисыннан чыгу өчен, ВКП(б) ҮК ның Генераль секретаре И. В. Сталинның тоташ күмәкләштерү турында күрсәтмәсе гамәлгә керә һәм авыл тарихында массакүләм коллективлаштыру чоры башлана.

Бу чор илебез һәм авыл тарихында кеше язмышлары трагедиясенең тагын бер этабы. Сүз дә юк, гомереңдә бер үз аты булмаган кешеләр өчен колхозның милкеннән файдалану, минемчә, уңай күренештер. Ләкин, күп кешеләрне, гомере буе тир түгеп, эшләп җыйган байлыкларыннан мәхрүм итү, аларның кеше буларак хокукларын чикләү, репрессия корбаннары итү юлы белән колхозлар барлыкка китерү – тискәре күренеш.

Озак еллар авыл советы секретаре булып эшләгән, хәзер инде мәрхүмә, Таһирова Гөлсем апа истәлекләрендә безнең авылда колхозлашу тарихы түбәндәгечә бәян ителә: «Күмәк хуҗалыкларга берләшү 1929 елда башланды. Колхозга беренче керүчеләр арасында Ахмадуллина Хәйрикамал, Хайбуллин Сәлах, Сөнгатуллина Шәмсекамал, Галиева Вәсимә һәм башкалар бар иде. Барлыгы 29 йорт күмәк хуҗалыкка берләште. **Ә 1932 елга бөтен хуҗалыклар да диярлек колхозга кереп бетте. Колхоз «Карл Маркс» исемен алды**. Колхоз шушы исемне йөрткән чорда, аның җитәкчеләре булып Хайбуллин Сәлах, Низамиев Бахау, Закиров Габдулла, Хамидуллин Гафият, Гатиятов Сәлим, Садриев Әбрар һәм Минһаҗев Хәлил абыйлар эшләде»

Мәктәп музеенда төрле чорда эшләгән колхоз җитәкчеләренә багышланган «Эш күрсәткән ирне ил онытмас» дигән экспозиция бар. Аларның олы фидякарь хезмәтен түбәндәге шигъри юллар белән тасвирлыйсы килә:

Күпләр туып – үсте монда
Монда чөйде җирәбәсен.
Кемдер кала, кемдер китә,
Аңламыйча җир бәясен
Тик шундыйлар кала монда
Елар чакта түзсә, көлсә,
Сукранмыйча күн итеген
Көн дә юып кия белсә.

Гөлсем апа истәлекләренә әйләнеп килсәк, күмәк хуҗалык өчен терлекләр һәм атлар һәр йорттан алынган (әгәр дә булса). Атлар дворы Вәлиев Мидхәтләрдә, аннары Шакиров Газыймҗаннар ишек алдында булган, Низам бай ызбасы башлангыч мәктәп иттертелгән.

Колхозга кермәүчеләр арасында урта хәлле крестьяннар да булган. Алар арасыннан Вәлиев Сафа, Сираҗиев Габдрахман, Шакир бабайлар, Әхмәтов Борһан, Мостафин Низам һәм Сәлах, Бадамшин Ногман «кулак» диеп игълан ителгәннәр. Бөтен мөлкәтләре тартып алынган Сафин Хафиз авылдан сөрелгән.

Партиянең әмере белән бит гел
Үтәде ул хаклык кушканны,

Нахак яла корбаны бит, бәгырь!-
Ничек булсын «халык дошманы»?!
Каберегез кайда, фида җаннар?
Күпме эзли сине Ил – Ватан!..
Кемнәр вөҗданында сезнең каннар!»…
Р. Әхмәтҗан «Эзе дә юк»

Гыйбадуллина Асия апа гаиләсенә колхозлашу һәм, тоташ коллективлаштыру сәясәтенең нәтиҗәләре бигрәк тә кагыла. Бу турыда үзе ул менә ничек искә ала: «Мөхәммәтсафа бай – минем бабам. Аның алты почмаклы зур өе, каралты – куралары, терлекләре булган. 1931 елның кышкы суыгында колхозга кермәгән өчен, бар мал – мөлкәтне тартып алып, бабамның гаиләсен, шул исәптән, минем әтине дә урамга куып чыгарганнар. Ә йорт колхоз идарәсе бинасына әйләнгән. Раскулачивать иткәч, Мөхәммәтсафа бабамны төрмәгә япканнар. Әтием, Хафиз, бу вакыт Мәскәүдә метро төзелешендә эшләгән, ә әбием чабатадан, бабаның төрмәгә эләгү хәбәрен әйтү өчен, эти янына килгән. Шуннан соң, әтием К. Ворошиловка мөрәҗәгать итеп, хәлне аңлаткан, һәм бабамның үлем карары 10 ел төрмә белән алыштырылган. Ә 1937 елда әтине дә кулга алганнар.

Шушы ук вакытта, **Әхмәтсафа бай гаиләсен дә «халык дошманы гаиләсе» дип авылдан сөргәннәр, ә үзен төрмәгә япканнар**. Бу гаилә 1955 елда авылга кире әйләнеп кайтты. Әтиләре нигезендә яңадан яхшы йорт җиткезделәр. Тырыш кешеләр кайда да югалмыйлар алар». Икенче әбием – Сафина Сара да бу турыда еш искә ала: «Безнең әтинең туган – тумачалары да репрессия корбаннары булдылар», - ди ул, - Әтинең абыйсы Миңнуллин Нәбиулла колхозлашу чорында төрмәгә эләгеп вафат булды, ә иң олы абыйлары Миңнуллин Галимулла 1937 елда 10 елга хөкем ителде: хезмәт һәм төзәтү лагерена җибәрелде. 1943 нче елның 1 маенда елда вафат булды. Дәүләтебез тарафыннан, гаебе булмау сәбәпле, 1990 елда акланды».

Гулаг лагерьлары корбаннары инде күбесе реабилитацияләнделәр. Ләкин шушы чор вакыйгаларын үз җилкәләрендә татучылар өчен бу еллар хатирәләре мәңгелек кайтаваз булып яңгырап тора.

Тарих сыры катлам – катлам
Хаклык кайда?
Кайда ялган?
Үткәннәргә күз төшерсәк,
Анык түгел хаклык һаман.

1927 елда оешкан Кайбыч районы республикада беренчеләрдән булып, «тоташ коллективлашкан» район дип игълан ителә. Авыл хуҗалыгын машина – трактор паркы белән тәэмин итү максатыннан, МТСлар оештыру - колхозлаштыруның прологы булып тора. Мөрәле авылы янында да оешкан МТС республикада алдынгылардан саналган. Авылдан күп кешеләр монда

тракторчы булып эшләгәннәр. Алар арасында хатын – кызлар да булган: Кадыйрова Рабыйга, Саттарова Хәфәзә, Тимуршина Сара, Насретдинова Зилә, Вәлиева Нурдидә. 1969 елда чыккан «Социалистик Татарстан» газетасында Нурдидә әби турында түбәндәге юллар бар: **«1933 елда республикабыз кырларында 304 трактористка, 38 комбайнерка, 26 хатын – кыз агроном эшләде. Колхоз производствосының комсомолка – трактористка Нурдидә Вәлиева (Мөрәле МТС) ы кебек бик яхшы ударницалары бөтен Татарстан буенча билгеле иде»**[1]

Ирләрдән трактор бригадиры булып эшләүчеләр: Нәҗиев Әхмәтсафа, Сабиров Кәбир, Гарифуллина Кәлимулла, Әдиятов Сәлимша, Мифтахов Нуретдин һәм бабам Вафин Рахимулла кебек үз эшләренең остазларын аеруча ассызыклар идек.

Безнең авыл –
Күздә корыган каен төсле,
Яз керде дә – өр – яңадан яфрак ярды.
Сука картның кабере өстендә сабан үсеп,
Үгезләргә тракторлар алмашынды.

М. Җәлил. «Безнең авыл»

30 еллар авыл тарихында халыкның рухи мирасын – динне зурлауны да юкка чыгару чоры ул. Мөрәледә 1870 елда мәчет төзелә. 1936 елда шушы ике катлы бинаның биек манарасын кисеп аударалар. Бу эшкә авыл кешеләре алынмагач, Багай авылыннан ике урысны яллыйлар. Мәчет фотосурәте әле дә сакланган.

[1] М. Рафиков “Тракторлар гөрелтесе”. - / “Социалистик Татарстан”, 1969. № 250.



1933 елда, җидееллык мәктәп янганнан соң, бу мәчет 1950 елга кадәр мәктәп ролен үти.



*Мәчет бинасын мәктәп итеп файдалануга рөхсәт – килешү документы. 1933 ел 23 декабрь.*

Ә Әхмәтсафа мулла йортын авыл клубына әйләндерәләр. Шөкер, актык елларда, дини традицияләребез кире әйләнеп кайта башлады. Элекке мәчетнең үз урынында ук яңа мәчет бинасы торгызылды. Йөрәкләргә иман нуры өстәп, азан тавышы яңгырый. Авыл картлары шушы мәчеткә җомга намазына йөриләр, төрле дини бәйрәмнәр үткәрәләр.

Мөрәле таңнары ата
Азан моңнары белән.
Һәр кешегә шатлык килсен
Иман нурлары белән.
(автор)

## • Авылыбыз Бөек Ватан Сугышы елларында

Исеңдә тот аларның син
Сугышларда кан түккәнен,
Туган жирнең иреге өчен
Зинданнарда интеккәнен.

## ***Батырлык үрнәкләре***

Бөек Ватан сугышында Җиңү һәм көрәш юлы озын, авыр була, ләкин батыр авылдашларыбыз әнә шул юлны дан белән узган, сугышның төрле фронтларында дошманга каршы аяусыз сугышып, тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән, Берлинга кадәр барып җитеп Җиңүгә зур өлеш керткән. Сугыш кырларында сынатмыйча батырларча көрәшкән 24 авылдашыбыз – орденнар, 132 е – медальләр белән бүләкләнгән. Сугыш корбаннарсыз булмый, изге көрәштә җиңү яулаганда, ут эчендә юл ярып алга барганда бик күпләрнең гомере өзелгән. Авылдан сугышка 270 кеше китә, шуларның 108 е кире әйләнеп кайтмый. Мисал өчен, бер **Тимуршина Фатыйма әбинең генә сугыш кырында биш баласы ятып калган**. 42дән артык авылдашыбызның һәлак булуы документ белән расланмаган, исемнәре “Хәтер китабы”на кертелмәгән. Әлеге бу эш дәвам итә, бәлки яңа исемнәр ачыкланыр. (Кушымта №2)

Җиңү көне якынлашкан саен
Яңаралар иске яралар
Кара тышлы хәтер китабыннан
Эзлим Сезне, кайтмый калганнар.




*Авылдашларыбызның фронт географиясе*

Татарстаннан сугышта 700 000 нән артык кеше катнашкан, 225 тән артык якташыбыз Советлар Союзы Герое исеменә лаек. Шулар арасында безнең район кешеләре дә бар: Ырым Тәрбите авылыннан Михаил Кузьмин, Зур Подберезьедан Андрей Кошкин, Турминский авлыннан Иван Федоров. Республикада 48 кеше – Дан орденнарының тулы кавалеры. Алар арасында Корноухово авылыннан Иван Субботин, Кичкеево авылыннан Василий Платонов, Шүширмәдә туган Тимерша Нәҗметдинов тә бар. 1944 елда Белоруссияне фашистлардан азат итүдәге батырлыклары өчен **Тимерша Нәҗметдинов** III дәрәҗә Дан ордены,ә Балтыйк буендагы батырлыклары өчен II дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә.Польшадагы Коббельбуде торак пункты өчен барган сугышларда дошманнның ике пулемет расчетын юк итә.Менә шуннан соң кыю сугышчы күкрәгендә I дәрәҗә Дан ордены балкый. (Кушымта №3)



**Тимерша Нәҗметдинов**

Үзебез авылдан сугышта батырлык үрнәкләре күрсәткән, Икенче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры, “Ленинградны саклаган өчен”, “Варшаваны азат иткән өчен”, “Германияне җиңгәне өчен” медальләре белән бүләкләнгән **Шафигуллин Фатыйх Борһан улы**-безнең горурлыгыбыз.Фатыйх абый Ленинградны,Латвияне, Польшаны азат итүдә катнаша.Берлинга ул взвод командиры булып бара.Сугыш тәмамлангач Германиянең Магдебург шәһәрендә хәрби хезмәткә кала.Сугыштан соң озак еллар мәктәбебезнең директоры булып эшләп,1980 елда лаеклы ялга чыга.



*Шәфигуллин Фатыйх Волхов фронты окопларында(алда).*

Мәктәп музеена ул сугышта йөрткән медальонын бүләк итте. Аның эчендәге пулялардан тишкәләнеп беткән, исем-фамилиясе язылган кәгазь кисәге музейда истәлекле ядъкар булып саклана.



*Шәфигуллин Фатыйхның сугыш медальоны*

Бөек Ватан сугышы тарихы белән бәйле экспозицияләр мәктәп музеенда шактый урын алып тора. Сугыш батырлары турында күп материаллар тупланган.

Шулар арасыннан Гәлләмов Кәбирнең сугышта йөрткән кырыну приборы, бал кашыгы һәм котелогы игътибарга лаек. Аны музейга Кәбир абыйның улы,мәктәбебездә физкультура укытучысы булып эшләгән Гәлләмов Фирдинат бүләк итте. Кәбир абый сугыштагы батырлыклары өчен Икенче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән.



*Гәлләмов Кәбирнең сугыш  котелогы.кырыну станогы,балкашыгы*

Авылдашыбыз Әхмәтҗанова Рокыя сугышта зенит артеллириясендә отделение командиры булып хезмәт итә. Иптәшләре белән бергә совет солдатларының Днепрны кичүен дошман самолетларыннан саклый, Киевны, Польшаның Познань шәһәрен азат итүдә катнаша. (Кушымта №4-5)




*Рокыя Әхмәтҗанова мәктәп укучылары арасында*

Сугыш елларында Татарстанда оешкан 18 нче, 146 нчы, 334 нче, 352 нче, 147 нче укчы дивизияләр, 120 нче укчы гвардия дивизиясе,91 нче аерым танк бригадасы, 37 нче  зенит - артиллерия полкы,Татарстан Югары Советы исемендәге 202 нче авиация дивизиясе сугышчылары яу кырында каһарманнарча нык торды. Дәһшәтле сугышта башын салган

авылдашларыбыз, татарстанлыларыбыз хәзер дә безнең арада кебек. Алар образы авыл уртасындагы һәйкәлдә гәүдәләндерелгән. Үлемсезлек символы булган солдат һәйкәле безгә дәшә кебек:

«Онытма син: бик кыйммәткә төште
Синең бәхетең безгә
Шул хакта гел сөйләп тору өчен,
Таш сын булып, һәйкәл булып
Кайттым бүген сезгә!»
Э. Мөэминова «Һәйкәл»



*Авыл уртасындагы обелиск күренеше*

## *“Ил язмышын салып иңнәренә “*

Сугыш вакытында тылдагы тормышның бөтен авырлыгы хатын-кызлар җилкәсенә төшә. Безнең “Карл Маркс” исемендәге колхозда 1944 нче елда иген кырларының һәр гектарыннан 3,62 ц уңыш җыеп алына. Бу елларда авылыбызның хатын-кызлары комбайн һәм трактор штурваллары артына утыра. Мөрәле МТСында тракторчы булып эшләгән Колыхаева Нүрдидә һәм башка хатын-кызларыбызның тырыш хезмәте Татарст ан тарихы дәреслекләрендә дә урын алган..

1941 елның 13 октябрендә СССР Дәүләт Оборона Комитеты республика җирендә, бөтен Идел буе кебек үк, оборона чикләре төзү турында карар чыгара. Моның төп максаты – шул чикләрдән файдаланып дошманны промышленность үзәге – Казанга кертмәү, ерактагы тылга да уздырмау була. Бу оборона чиге безнең Кайбыч, Апас районнары,Чувашстанның Урмары станциясе, Мари иленең Звенигово авылы аша үткән аша үткән.Тарихта ул **“Казан каймасы”**дигән исем алган. Авылыбызның бик күп хатын – кызлары шул оборона чикләре – окоплар казуда катнашканнар. Зәмһәрир суыкларда

тәүлегенә 14 әр сәгать эшләгәннәр.Фашист танкларына каршы тору өчен республика буйлап 331 чакрым озынлыкта окоп казыла, 392 күзәтү пункты, 98 яшерен ут һәм 56 зенит нокталары, 419 землянка булдырыла. Окоп казуда катнашкан якташларыбызның батырлыгы, фидакарьлеге сугышта катнашканнарныкына тиң. Дан һәм хөрмәт аларга!(Кушымта №6)

Оборона фондына ярдәм йөзеннән авыл хезмәтчәннәре икмәк, ит, сөт, яшелчә, акча һәм җылы киемнәр тапшыралар.Татарстан хезмәт ияләре фронтка 23 меңләп кыска тун, 54 мең пар киез итек, 59 мең телогрейка, 106 мең пар күлмәк-ыштан озатканнар икән,монда безнең авылдашларыбызның да өлеше бар. Безнең Кайбыч районы колхозчылары, республикада беречеләрдән булып кызыл армиянең җиңү фондына акча җыю инициативасы белән чыгалар һәм үзләре 1 млн.300 мең сум акча җыеп шушы фондка кертәләр.




*Сугыш елларында тылда хезмәт иткән һәм сугышта катнашкан ветераннарыбыз белән мәктәптә очрашу мизгеле. Сулдан уңга: Шагивалиева Әминә, Тимершина Фәрзанә һәм зенитчы Ахметзянова Рокыя.*

**ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты бюросы утырышы беркетмәсеннән**

1. Үзләренең иҗтимагый бурычларын яхшы аңлап, Кызыл Армия җиңү фондын төзүдә патриотик башлангыч күрсәтеп, 1300 мең сум акча керткән Кайбыч районы колхозчылары башлангычын хупларга һәм аңа булышлык итәргә.

2. ВКП(б)ның шәһәр һәм район комитетларына Кызыл Армиянең җиңү фондын төзү буенча массакүләм-сәяси эш җәелдерергә, колхозчылар, тракторчылар, комбайнчылар, предприятиеләр, МТСлар һәм совхоз эшчеләре һәм хезмәткәрләренең җыелышларын уздырырга, бу мөһим хуҗалык-сәяси чарада коммунистларның, комсомолларның һәм партиясез активның әйдәүче һәм оештыручы ролен тәэмин итәргә.

3. "Красная Татария", "Кызыл Татарстан", "Херле Ялав" газеталары редакцияләренә, район газеталары редакторларына Кызыл Армия җиңү фондын төзү чараларын киң яктыртырга, гитлерчы басып алучыларны тулысынча җиңү эшен тәэмин итәр өчен көчләрен һәм акчаларын бирүче алдынгы предприятиеләр һәм колхозларны, иң яхшы патриотларны чагылдырырга тәкъдим итәргә.

*Татарстан коммунисты. 1990. № 5. 54б.*

Шулай ук безнең районнан жыелган икмәк һәм акчага ПЕ – 8 бомбардировщигы төзелә һәм бу очкыч Советлар Союзы Герое Обухов экипажына бирелә. Ә фронтка ярдәм итү өчен районнан җыелган икмәкне Казанга алып барып тапшыру вәкаләте безнең авылдашыбыз, ул чагында Кушкүл авылында колхоз рәисе булып эшләүче Фәйзиева Миңкамалга йөкләтелгән. Республика буйлап җыелган икмәк һәм акчага «Кызыл Татарстан» исемендәге танк колоннасы төзелгән.



ВАТАН НАМУСЫ ӨЧЕН

КЫЗЫЛАРМЕЕЦЛАР ГАЗЕТАСЫ

Красноармейская газета «ЗА ЧЕСТЬ РОДИНЫ» на татарском языке

№ 25 (214) ДҮШӘМБЕ 3 АПРЕЛЬ 1944 ел.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

**Дәүләт Оборона Комитеты Председателе иптәш СТАЛИНГА**

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Көн саен яңадан-яңа шәһәрләрне һәм авылларны немец-кабахәтләрдән азат итә барган данлыклы Кызыл Армиянең гүзәл җиңүләре хезмәт ияләренең йөрәкләрендә соклану һәм Ленин—Сталин партиясе тарафыннан, иптәш Сталин, Сезнең тарафтан тәрбияләп үстерелгән куркусыз герой сугышчылар белән горурлану хисе тудыра.

Татарстан республикасы хезмәт ияләре Кызыл Армиянең җиңүләренә производствода яңа уңышларга ирешү белән җавап бирәләр. Дошманны тар-мар итүне барлык көчләре белән тизләтергә теләп, Татарстан республикасының эшчеләре, колхозчылары, колхозчы хатын-кызлары, инженер-техник работниклары һәм интеллигенциясе Кызыл Армиянең җиңү фондына «Кызыл Татарстан» исемендә танклар колоннасы төзүгә 62.000.000 сум акча керттеләр. Средстволар керүдә дәвам итә.

Татарстан хезмәт ияләренең саклык акчаларына төзелгән дәһшәтле машиналар фашист-кабахәтләрне рәхимсез тар-мар итсеннәр һәм юк итсеннәр.

Яшәсен героик Кызыл Армия!

Яшәсен бөек Сталин!

Ж

КАЗАН,

**Татарстан АССРның Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш ШӘРӘФИЕВКӘ ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре иптәш НИКИТИНГА**

... Татарс... исемендә танклар колоннасы ...ча җыйнаган Татарстан Авто... ...тик Республикасы хезмәт ия... ...емне һәм Кызыл Армиянең

Әбием,Сафина Сара шушы еллардагы вакыйгаларны болай искә ала: «Сугыш вакытында тормышның бөтен авырлыгы хатын – кызлар җилкәсенә төште. Иген кырларында игенне кулдан урдылар. Тора – бара колхозга ура торган самобрускалар, лобогрейкалар кайтты. Колхозчы хатын-кызлар көлтәләрне кибәнгә куялар һәм шуннан көлтәнең җебен кисеп молотилкага салалар иде. Суктырылган игенне вилкалар, көрәкләр белән чистарталар. Икмәк дәүләт заданиесен үтәргә, натуралата тапшыруга китә иде.

Озакламый әнием авырып китте, ә әтием сугышка китеп барды. Без – биш бала – авыру әниебез белән калдык. Абыем Кәрибулла 1926 нчы елгы. Әтиебез киткәндә, миңа 12, ә абыйга 15 яшь иде. Кәрибулла абыем колхозга сабанчы булып эшкә керде. Озакламый ул да сугышка китеп барды. Ике ел

Горький өлкәсенең Кулибаки дигән шәһәрендә төз ату һөнәренә укыды.Ачлыктан интеккән абый янына әни,авыру килеш ике тапкыр барды, капчык-капчык сохари алып китте. Фронтка киткәч, алар, дүрт малай:Кәрибулла абый, Биктагиров Минхәбир, Саттаров Салих, Кузнецов Николай, пленга эләккәннәр. Шуннан соң озакламый, гаиләбезгә абыйның үлүе турында хәбәр килде. Бу хәбәрне ишетү барыбызга да бик авыр тәэсир итте: әни урынга ук егылды. Бер ел да ике көннән соң абыйдан хат килеп төште. Исәнлеген белгәч, куанычыбызның чиге булмады. Озакламый, исән - сау килеш, үзе дә кайтып керде.

1941-1943 елгы ачлык безнең гаиләне читләтеп үтте дисәк, ялгыш булмас. Чөнки абыемның эшләгәненә 18 пот икмәк алдык, шуның белән без ачлыкны бик күрмәдек. Ә авылдашлар арасында ачлыктан шешенеп үлүчеләр дә булды. Мәсәлән, Миңнуллина Сорүзҗиһан әбинең җиде баласы бодай ашап агуланып үлделәр. Яз көнне калган икмәкне җыеп кайтып, эчерек бәрәңге ашап яшәдек.

Сугыш еллары гомеремнең иң авыр чагы булгандыр, мөгаен. Үгезләр җигеп җирләр себертә идек, кечкенә арбалар белән симәнә ташыдык. Шуны, дәүләт заданиесен үтәр өчен арба белән Коланғыга алып бара идек.Икмәк капчыкларын җилкәгә салып вагоннарга төйи идек. Ә инде кич җиткәч иң куркынычы башлана иде: авыл өстеннән самолётлар оча башлый. 10 йортка бер каравылчы. Әзрәк утың күренсә, тәрәзәгә шакыйлар, калган очракларда кисәтү бомбалары ташлыйлар иде. Бәхеткә, бездә бомбага тоту очрагы булмады. Өйдәге лампа уты күренмәс өчен, булган барлык шаламалар белән тәрәзәне эчке яктан томалый идек». Бу чыннан да шулай.1941 елның 13 сентябреннән Апас,Буа,Чүпрәле,Кайбыч,КамаТамагы, Тәтеш,Тархан районнарында тулысынча саклану режимы кертелә.

Авылдаш хатын-кызларыбызның тиңдәшсез батырлыгына мәдхия җырлап тарих фәннәре кандидаты **Тәэминә Биктимерованың** “Ил язмышын салып иңнәренә...” дип исемләнгән китабыннан өзек китерәсе килә: **“Гомерем буена мин сугыш елларында газап чиккән хатын-кызларга һәйкәл кую турында хыялланам. Күз алдыма завод цехларында көнне төнгә ялгап эшләгән апалар яки сыер җигеп сука сукалаган, карлы-бозлы юллардан җилкәсенә асып, я булмаса чана тартып чәчүлек орлык ташыган әниләр, киленнәр, кызлар килеп баса. Я алар янына без ятимнәрне кызганып, җаннары өзгәләнән яшь кенә укытучы апалар, кабинасыз тракторда көнен төнен бер итеп эшләп иген үстергән тракторчы кызлар, сугыш кырында ятып калган газизенең исәнлегенә өметен өзмәгән, күз нурларын түгеп, сукыр лампа яктысында фронттагылар өчен җылы оекбаш, бияләйләр бәйләгән әниләр, әбиләр килеп баса. Һәркайсына зур мәйданнарның уртасына бастырып һәйкәлләр куясы иде, һәркайсына багышлап аларны искә төшереп торырдай моңлы җырлар чыгарасы иде.”**

# *“Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр...”*

Хатлар, хатлар... Өчпочмаклы, читенә кыр почтасының тәртип саны куелган, штемпель сугылган хатлар... Солдат хатлары... Кыскка гына ял вакытында язылган әлеге солдат хатларында дошманга булган ачы нәфрәт тә, Туган илгә булган мәхәббәт тә, туганнарга карата булган җылы хисләр дә, сугыш авырлыгы, яраларның сызлавы – барысы да сыеп беткән.

Ел саен эзләнү эше язу өчен әзерлек эшләре алып барганда, «Яшь тарихчы» студиясенең членнары сугыш чоры турында шактый гына информация туплыйлар. Шулар арасыннан, кул астында булган бер газета мәкаләсенә тукталасым килә. Ул «Хроника фронтовой жизни сибиряка Харитона Хазиевича Галеева в письмах» дип атала. Бу мәкалә Красноярск крае үзәгендә чыга торган «Дзержинец» газетасыннан алынды. Кем соң ул – Харитон Галиев? Ул безнең авылдашыбыз. Аның чын исеме – Хаҗиәхмәт Зариф улы Галиев. 1921 елгы ачлык аны һәм аның өч кыз туганын Красноярск якларына китереп чыгара. Шушы крайда соранып йөри торгач, ул яхшы кешеләр белән очраша. Укып белем ала, Денисово авылында партия оешмасы секретаре һәм колхоз рәисе булып эшли. Ленинград Югары партия мәктәбен тәмамлап, райком секретаре дәрәҗәсенә күтәрелә. Ләкин дәһшәтле сугыш аның планнарын җимерә. Хатыны Лиза, ике улын һәм бер кызын калдырып, Хәҗиәхмәт Зариф улы сугышка китә. 1943 елның августында фронттан аның хәбәрсез югалуы турында хәбәр килә. Бу кешенең Ватанга ни дәрәҗәдә бирелгән булуы турында Ленинград оборонасыннан хатынына язган хатлары сөйлиләр. Без, студия әгъзалары, Хаҗиәхмәт абыйның оныгы Валентина белән һәрдаим хәбәрләшеп торабыз. Ә авылда Хаҗиәхмәт абыйның сеңлесе кызы Гыйбадуллина Азалия яши.

- Авылыбыз тарихы 1950 – 2000 елларда

Сугыштан соң, авыл озак тернәкләнә. 1946 ел гадәттән тыш коры килә. Уңыш сугышка кадәргедән ике мәртәбә азрак алына, бу исә авыл җирендә массакүләм ачлыкка китерә. 1948 – 1949 елларда да корылык була. Сугыш елларында бөлгән авыл өчен табигый бәлаләргә каршы тору бик авырга туры килә. Колхозчылар өчен хезмәт көннәренең мәҗбүри минимумы сугыш вакытында кертелгән булуга карамастан, һаман яшәп килә. Шәхси ярдәмче хуҗалыкны тоту да авыл халкына бик авырга туры килә, чөнки салымнар кискен арта. Ә эшләгән өчен түләү 6 нчы бишьеллыкта гына кертелә. Бер көнгә биш тиен хезмәт хакы туры килгән. Шундый авыр тормыш шартларында кайбер колхозчылар кырдан кайтканда кесәләренә башак салып кайткалаганнар. Шушы юк кына гаеп эш җинаять дип саналган. Гыйниятов Ярулла, Гыйбадуллин Кәлимулла Сталин лагерьлары аша үткәннәр - ГУЛАГ системасы сугыштан соң да чәчәк аткан.

Н. С. Хрущев идарәсе елларында авыл хуҗалыгы продукциясенә сатып алу бәяләре артса да, дәүләт шәхси хуҗалыкларга налог размерын арттыра. Хәтта, алмагачларга да налог түләтәләр, мәҗбүри займнар да кертелә.

Укытучы Хамидуллина Наилә апа бу еллар турында болай искә ала: «Без, укытучылар – агитаторлар, еш кына авыл башына, станциягә илтә торган юл кырыена барып баса идек. Максатыбыз – ит, йомырка, сөт сатырга баручы килеп чыкса, бу кешене кире бору һәм продуктларын налог өчен дәүләткә алып калу иде»

1958 елдан Мөрәле МТСы бетерелә, колхозның үзенә машина - тракторлар бирелә. Шәхси хуҗалыкларда терлек асрау арттырыла. Ләкин кайбер елларда, урындагы хакимият «Авыл хуҗалыгы Артеле Уставында каралганнан артык терлек тотарга ярамый», - дигән карар чыгара. Шуннан соң, терлекләрне өйгә кереп җыеп йөргәннәр. Гыйбадуллин Галим абый бу турыда әле дә ачынып сөйли.

Колхозларны эреләндерү сәясәте башлангач, Федоровское авылын да кертеп, 1961 елдан колхоз «Память Ленина» исемен йөртә башлый һәм 1989 елга кадәр шул исем белән яши. 1961елдан 1981 елга кадэр колхозны намуслы, тырыш хезмәткәр Евгений Тутаев җитәкли.

1990 елда Кайбыч районы яңадан оешты. Мөрәле авылы «Память Ленина» колхозы составыннан аерылып чыгып, «Урожай» колхозы исеме белән йөртелә башлады. Колхозны, аның язмышы өчен җаны – тәне белән көеп йөрүче, Сибгатов Фәргать җитәкләде. «Урожай» колхозының кырлары районда иң чиста культуралы кыр диеп табылды, колхозда республика агрономнарының семинар киңәшмәсе уздырылды һәм анда колхозның эш тәҗрибәсе белән уртаклаштылар.

«Урожай» колхозы кырларында, яңа төзелешләрдә, мәктәптә, мәчеттә ул чактагы президентыбыз Минтимер Шәймиев булды һәм колхозчылар хезмәтенә уңай бәя бирде.

90 нчы елларга күмәк хуҗалыкларга мөстәкыйльлек алу, базар мөнәсәбәтләренә күчү тенденциясе хас. Шундый шартларда авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу бәяләре түбән булу хуҗалыкларының икътисади хәленә зур йогынты ясады. Сатылган продукциягә акча алмау колхозчылар белән исәп – хисап ясауны авырлаштырды.

Авыл хуҗалыгын инвестицияләүгә уңайлыклар тудыру, крестьяннарның тормыш хәлен яхшырту максатыннан 2003 елда колхоз милке, җаваплылыгы чикләнгән «Алтын башак» Ышану Ширкәте карамагына күчте(хәзер "Кайбыч-1" җәмгыяте), һәм уңай күренешләр дә сизелә башлады.

Авылыбыз кешеләре үзләренең мактаулы эшләре белән данлыклы. Музеебызның «Горурланам авылым синең белән, тудыргансың данлы кешеләр», «Хөрмәт төбе – хезмәт» исемле экспозицияләрендә шушы кешеләрнең фотосурәтләре һәм биографияләре яктыртылган. Алар арсында Почет билгесе ордены кавалеры, 40 ел сыер савучы булып эшләгән Хисамиева Мәдинә Хәлил кызы, Хезмәт Кызыл Байрак ордены кавалеры, ТАССРның атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы Сираҗиев Тәлгать Габдрахман улы, Кызыл Байрак ордены кавалеры Шәфигуллин Фатыйх Баһаветдин улы, Хезмәт Кызыл ордены кавалеры, ТАССРның атказанган машина төзүчесе Нәҗиев Фәрит Сафа улы, Ленин ордены кавалерлары Вәлиуллин Хәмидулла Вәлиулла улы, Сәлахов Афзал Сәлах улы һәм башкалар бар.

## 5. Мәктәбем – белем бишегем

Мәктәп – гыйлем чишмәсе ул,
Изге аның исеме.
Караңгыдан тартып алып
Нурландыра кешене.
(автор)



Мәктәбебезнең гомуми күренеше.

Мөрәле мәктәбе тарихы еракка, 19 гасырга барып тоташа. 1925 елга кадәр һәм аннан соңгы чорда авылда күл буенда урнашкан мәдрәсә эшләп килә. Башта ул земство башлангыч мәктәбе ролен үтәгән. Мәдрәсәгә әйләнгәч, анда Шәфигуллин Ярулла хәлфәлек иткән.

Ярулла бабай нәселе укымышлы нәсел булган. Аның әтисе дә Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф укыган чорда, аннан ике сыйныф түбән аерымлык белән, атаклы Кышкар мәдрәсәсендә белем алган. Шәфигулла абыйдан укытучылык итү традициясе Ярулла абыйга, ә Ярулла абыйдан кызы Рәшидә апага күчкән. Ул да 40 елдан артык туган мәктәбебездә мөгаллимлек иткән.

1926 – 1934 елларда авылда җидееллык мәктәп эшли. Бу мәктәп Свияжск кантонында иң зур мәктәпләрнең берсе була. Бу чорда мәктәптә курчак театры артистлары арасыннан Татарстанның беренче халык артисты Фуат Таһиров, язучы Гали Хуҗиев белем ала. 1933 елның гыйнварендә җидееллык мәктәп ябып китә. Шуннан соң, авыл мәчетенең манарасын кисеп, мәчетне мәктәп итәләр. Ул унъеллык мәктәпкә әйләнә. Ә 1939 елдан монда башлангыч сыйныфлар гына кала. 1950 елда яңа җидееллык мәктәп бинасы өлгертелә. 1958 елдан ул сигезеллык мәктәпкә әйләнә. Бу мәктәпнең директорлары булып, Ахмеров Әхмәт, И. Козлов, Е. Кошкин, Шарафутдинов Шәхретдин абыйлар эшләгәннәр. **Безнең мәктәптә 1954 – 1958 елларда**

**атаклы татар язучысы Самат Шакир мәктәп коллективын җитәкли**. 1960 елдан 1980 елга кадәр безнең мәктәбебезнең директоры булып Шәфигуллин Фатыйх Баһаутдин улы эшли. Ул Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм “Германия өстеннән җиңү”, “Варшаваны азат итү өчен” медальләре, Кызыл Йолдыз (№758482), II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы (№349289) орденнары белән бүләкләнгән. Бу мәктәп бинасын хәзергесе белән чагыштырам да, мәктәп җитәкеләренең хезмәте нинди авыр булганлыгы турында уйлыйм. Алар хәзер мәрхүм инде, ләкин мәктәп бусагалары буйлап атлаганда, мин алар өчен горурлык хисләре кичерәм. Мәгърифәт учагы буларак, мәктәп бүгенге көндә авылны яшәртүче һәм яшәтүче төп көч.



Шәфигуллин Фатыйх Баһаутдин – икенче рәттә, сулдан беренче.
Иске мәктәп бинасы күренеше.1955 ел

## 6. Горурланам авылым синең белән Үстергәнсең данлы кешеләр…

Һәр төбәкнең, аның данын ераkларга җибәрә торган абруйлы шәхесләре, зыялылары була. Кырлай, Сыркыды, Күлле – Киме, Әнәкләргә тиңләшмәсә дә, безнең авылдан да билгеле бер шәхесләр чыккан. Җәмгыятькә файда китерү ягыннан карасак, ул - сыер савучымы, механизатормы, галимме, рәссаммы, һәрбер кеше хезмәте данлыклы. Ләкин, минемчә, авыл данын еракларга таратучылар, алар – зыялы шәхесләребез. Шуларның кайберләренең биографиясенә минем аеруча тукталып китәсем килә.

**Сәлахов Мингалим Афзал улы** – 1940 елда безнең авылда дөньяга килгән, шушында җидееллык мәктәпне тәмамлаган. Мәскәү авиация институтын бетереп, техник фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә күтәрелгән, озак еллар С. Королев исемендәге Космик тикшеренүләр Үзәгендә эшләгән. Ул - Роальд Сәгъдиевның хезмәттәше, һавада хәрби самолетларны очучысы юк килеш буксирлау буенча 100 дән артык фәнни хезмәтләр авторы, Россиянең атказанган рационализаторы.

Узган ел Мингалим абый белән мәктәп музеенда очрашу булып узды, ә аннан алдагы елда 1 сентябрь – Белем бәйрәме көнендә ул мәктәпкә кунак булып килде. Мәскәү шәһәрендә яшәвенә дә карамастан, ул безнең белән араны бер дә өзми. Техник белемле  булса да, бу кешенең рухи яктан бай шәхес булуына таң каласың. Улы  Марат та – абруйлы шәхес: Россия эчке эшләр министрлыгының үзәк аппаратында эшли: «Элекке министр Рәшит Нургалиевның уң кулы иде ул», - ди горурланып, Мингалим ага.

Мингалим абыйның әтисе Афзал абый да – авылыбызның горурлыгы. Мөрәледә бик күпләр аны «Стахановчы бабай» дип йөрткәннәр. Афзал абый Донбасста, Донецкта, Чиләбе өлкәсендәге Аша металлургия заводларында 24 ел металлург булып эшләгән. Тырыш хезмәте өчен, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, ә 1954 елда Ленин ордены белән бүләкләнә. «Афзал ага кебек хезмәт батырлары – хаклы рәвештә олы горурлыгыбыз булырга тиешле кешеләр.[1]

---

1 А. Сункишев. “ Утлы һөнәрне үз итеп”. - / “Кайбыч таңнары”, 2003, № 64.




*Сәлахов Мингалим Мөрәле мәктәбе укучылары каршында чыгыш ясый(сулда)*

Мифтахов

Һава һөҗүменнән саклану гаскәрләре генералы **Илмас Нуретдин улы Мифтахов** та – безнең авылдашыбыз. Туган нигезенә кайткач – ул мәктәбебезнең олы кунагы. Хәрби хезмәт юлы турында аның кызыклы итеп сөйләве күңелләрдә уелып калган. «1961 елның апрелендә Саратов далаларында очучы космонавт Юрий Гагаринны каршылавыбызны һич онытасым юк. Без, хәрби училище курсантлары, аның иминлеге өчен җаваплы идек. Шул ук елда Свердловск өстендә зенит – ракета девизионы тарафыннан АКШның У-2 шпион – самолеты бәреп төшерелү миндә үз профессиям белән горурлану уятты», - ди генерал. Хәзер, яшьләр Ватанны сакларга атлыгып тормаган чорда, генералның чыгышлары бездә, бигрәк тә ир – егетләрдә, хәрби көчләребезгә ышаныч һәм мәхәббәт тәрбияли.


6 Vatanым Tatarstan

Мөрәле егете

Татар генераллары

Санкт – Петербург шәһәрендә яшәүче атаклы рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, өч меңнән артык рәсем сәнгате әсәрләре авторы **Рәшит Гыйләҗевның** да тамырлары Мөрәле авылына килеп тоташа. Аның әтисе – Әкмал Гыйләҗ улы 1919 елда, әнисе Гайшә Нәсретдин кызы 1922 елда Мөрәле авылында туган.

Үзе Рәшит Гыйләҗев Яшел Үзән шәһәрендә туа, аңа 9 яшь тулгач, гаиләләре Яр Чаллы шәһәренә күченә. Яшьтән үк рәсем сәнгате белән кызыксына. Бу талант аңа әнисе Гайшә ападан килгән. Ул да матур рәсемнәр белән сандыклар бизи торган булган. Рәшит Гыйләҗев башта Лениногорск сәнгать училищесында, ә соңрак, белемнәре белән канәгать булмау сәбәпле, Ленинград шәһәрендәге Рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтында укый. 1988 елда ул СССР Рәссамнар Союзының Ленинград бүлекчәсенә әгъза итеп кабул ителә.
90 еллар аның өчен аеруча уңышлы була. Рәссам Италиядә, Бельгиядә, Австриядә, Татарстанда сәяхәт итә. Рәшит Гыйләҗевның шәхси күргәзмәләре чын мәгънәсендә уңыш казана.



*Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев белән очрашу вакытында. Санкт – Петербург. 1996 ел.*

Хатыны Халидә ханым белән чираттагы кайтуларында алар туган мәктәбебездә булып киттеләр. Бу рәссамның төсләр дөньясын, чын мәгънәсендә, үзен күргәч кенә аңлыйсың. Рәссам пейзаж, натюрморт, портретлардан торган серияләр иҗат итә. «Татарстанны сурәтләргә тотынсам, үземнең сагынулы, моңсу хисләремә, хатирәләремә рәхәтләнеп ирек бирәм», - ди ул. Бу аның күңеленең нечкә, бай булуы хакында сөйли. Хәер, искиткеч гүзәл табигатен чын хезмәт кешеләре арасында үсеп дөньяга карашын формалаштырырга ярдәм иткән Мөрәле төбәген үз иткән сәләтле якташыбызның иҗаты башкача була да алмый.

2016 ел - бөек Тукаебызның юбилее елы . Үземнең авылыма катнашы булмаса да, Габдулла Тукай тормышы эпизодлары безнең район җирлегендә туып үскән кайбер кешеләр белән турыдан – туры бәйләнгән.

Безнең авылдан ерак түгел Кече Кайбыч авылы бар. Бу авылда мәшһүр татар опера җырчысы, Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкаяның әтисе Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин дөньяга килгән. Ә бөек Тукаебызның Уральск шәһәрендәге язмышы Мотыйгулла хәзрәт гаиләсе белән тирән үрелгән.

Габдулла Тукай бу шәһәрдә Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә белем ала. Булачак язучы, шушы мәдрәсәдә белем алу белән беррәттән, хәреф җыючы һөнәренә өйрәнә, беренче шигырьләрен яза башлый. Мотыйгулла хәзрәтне Тукайның әдәби остазы дип әйтергә тулы нигез бар.

Яшь Тукай Мотыйгулла хәзрәтнең малае Камил белән дуслаша. Камил Мотыйгый җитәкчелек итә торган «Уралец» газетасында Тукай наборщик булып эшли. «Әл – гасрел – җәдит», «Уклар» журналларында үзенең шигырьләрен бастыра, «Фикер» газетасында редактор вазыйфасын башкара. Камил Мотыйгый типографиясен башка кешеләр сатып алгач, **Габдулла Тукай Габдулла Хайруллин (Габдулла Кариев – булачак «Сәйәр» труппасы артисты) белән бергә Камил Мотыйгый библиотекасындагы китапларны сатып көн күрәләр. Камил Мотыйгый моны үзенең «Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында истәлекләрем» дигән язмасында бәян итә.**[1]

1907 елда Тукай Казанга әйләнеп кайта һәм гомеренең ахыргы көннәренә кадәр Мотыйгулла хәзрәт һәм Камил Мотыйгый турында бик җылы итеп искә ала.

Галия Кайбицкая Казанга килгәч, беренче эш итеп Яңа Татар бистәсендәге зиратта Тукай рухына дога кыла. Кыска гына гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган Тукай кебек, Галия Кайбицкая да үз эшенә тугрылыклы булырга антын бирә, һәм шул антына тугрылыклы калып, республикабызның мәшһүр җырчысына әверелә. Габдулла Тукайның бөек язучы булып җитлегүендә безнең якта туып үскән шәхесләрнең дә өлеше булуы белән без чиксез горурланабыз!

---

1 Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр. – Казан: 2002. – 420 бит.

## V. Йомгаклау

Шактый күләмле конкурс эшендә авыл тарихына тукталып, шул вакыт булган вакыйгаларга бәя бирергә тырыштым.

Һәр чор үзенчә үзенчәлекле, ләкин элек – электән тарихи алгарышның (прогрессның) нигезендә бәһаләп бетергесез кеше эшчәнлеге ята. Бу – тарихи закончалык. Һәр кеше турында, аның бөтен бөеклеген күз алдында тотып кайгыртсак – халык үлмәс. **Әгәр кеше үзе турында да Тукаебыз язганча: «Үзем үлсәм дә, гаҗиз исемем үлмәсен, югалмасын; минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен», - дип уйлап яшәсә, буыннар чылбыры өзелмәс, авыл тарихы дәвам итер.**

Кеше беренче чиратта үз намусы алдында җаваплы булырга тиеш. Шулай булганда гына тарихтагы «ак таплар» аз булыр.

**Ничек кенә еллар килмәсеннәр**
**Кара булсын алар…**
**Ак булсын...**
**Үз иманы белән яши адәм,**
**Үз иманы гына хак булсын.**

Кадыйр Сибгатуллин «Туфан белән сөйләшү»

Авылым елъязмасын язасы да язасы… Чөнки авыл яши, аның рухи сулышы сүрелми.

**Гавамга мирас – моң, сагыш,**
**Менә калган байлык.**
**Шулай да әле халыкта гамь,**
**Байтак Тукайлык**.

Р. Фәйзуллин

## VI. Кулланылган әдәбият:


1. Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: “Хәтер”, 2002.
2. Ф. Гарипова. Авыллар һәм калалар тарихыннан. – Казан, 1997.
3. Р. Гилазов. Живопись. – Петрополь, Санкт – Петербург, 2003.
4. Г. М. Мустафина. Татарстан тарихы. XIX гасыр. – Казан, Мәгариф, 2004.
5. К. Р. Синицына. Татарстан һәм татар халкы тарихы. – Казан: “Мәгариф”, 2001.
6. Дәүләт Оборона Комитеты Председателе иптәш Сталинга. –
7. / “Ватан намусы өчен”. - / Кызылармеецлар газетасы, 1944 ел, №25.
8. М. Рафиков “Тракторлар гөрелтесе”. - / “Социалистик Татарстан”, 1969. № 250.
9. А. Сункишев. “ Утлы һөнәрне үз итеп”. - / “Кайбыч таңнары”, 2003, № 64.
10. Ә.Садриев.”Халкыбыз каһарманлыгы мәңгелек”.-/”Мәгариф”2013 ел, №5.
11. Мәктәп музее фонды материаллары.

Кушымта №

# *Музей эшчәнлеге укучыларның эзләнү-тикшеренү эшләрендә*

Кушымта №

# *Музей эшчәнлеге - периодикада*